**МИНИСТЕРСТВО СПОРТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ СПОРТ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

*28.06.2019* Казан ш. № *196*

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы чараларына журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен раслау турында

1991 елның 27 декабрендә кабул ителгән 2124-1 номерлы «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Россия Федерациясе Законының 48 маддәсе нигезендә

**боерам**:

1. Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы чараларына журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләрен расларга.
2. Әлеге Боерыкның үтәлешен тикшерүне министрның беренче урынбасары Х.Х. Шәйхетдиновка йөкләргә.

Министр В.А.Леонов

Татарстан Республикасы
Спорт министрлыгының
28.06.2019дан 196 номерлы
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы чараларына
журналистларны аккредитацияләү кагыйдәләре

## I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге кагыйдәләр 1991 елның 27 декабреннән 2124-1 номерлы «Массакүләм мәгълүмат чаралары турында» Россия Федерациясе Законының 48 маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы каршында массакүләм мәгълүмат чаралары журналистларын аккредитацияләү тәртибен (алга таба – аккредитация, министрлык) регламентлый.

1.2. Аккредитация срогы чикләнмәгән. Редакция теләге буенча массакүләм мәгълүмат чараларын аккредитацияләү конкрет редакция биремен үтәү өчен кирәк булган вакытка яисә аккредитацияләнгән журналист вакытлыча булмаган очракта аны алыштыру (вакытлы аккредитация) өчен башкарылырга мөмкин.

## II. Аккредитациягә хокук

2.1. Милек формасына һәм гамәлгә куючыларның составына бәйсез рәвештә аккредитациягә массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләре, шул исәптән чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары хокуклы. Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен аның Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитацияләнүен раслату кирәк.

## III. Аккредитация тәртибе

3.1. Аккредитацияләүгә гариза министрлыкка массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенең җитәкчесе имзасы белән Министрлык тарафыннан күрсәтелгән гаризаны алу фактын, датасын һәм вакытын расларга мөмкинлек бирүче теләсә кайсы ысул белән тапшырыла.

3.2. Гаризада журналистның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), вазыйфасы, эш һәм кәрәзле телефоннары, электрон почта адресы, массакүләм мәгълүмат чарасының тулы исеме, массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү турындагы таныклыкның датасы һәм номеры күрсәтелә.

Вакытлы аккредитациягә гаризада шулай ук редакция биреме һәм аны үтәү чоры күрсәтелә, ә вакытлыча булмау сәбәпле аккредитацияләнгән журналистны алыштырган очракта – аның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта) һәм аны алмаштыра торган журналистны аккредитацияләү

вакыты күрсәтелә.

Чит ил массакүләм мәгълүмат чаралары журналистын аккредитацияләү өчен өстәмә рәвештә Россия Федерациясе Тышкы эшләр министрлыгы каршында аккредитациләнүен раслый торган документларның күчермәләре куела.

3.3. Әлеге Кагыйдәләрнең 3.2 пункты таләпләренә туры килми торган гаризалар каралмый.

3.4. Аккредитация турында (аккредитацияләүдән баш тарту турында) карар Татарстан Республикасы спорт министры (алга таба – министр) (аның вазыйфаларын башкаручы зат) тарафыннан гариза кергән көннән соң ике эш көненнән дә соңга калмыйча кабул ителә. Мондый карар, тиешле боерык чыккан көннән соңгы эш көненнән дә соңга калмыйча, гариза җибәргән массакүләм мәгълүмат чарасы редакциясенә аны алу фактын, датасын һәм вакытын редакция тарафыннан расларга мөмкинлек бирүче теләсә нинди ысул белән җиткерелә.

3.5. Массакүләм мәгълүмат чарасы махсуслашкан характерда булган очракта (реклама тарату, эротик басмалар) аккредитацияләүдән баш тартыла.

3.6. Аккредитация турындагы гаризаны карау, министрның аккредитация (аккредитацияләүдән баш тарту) турында боерыгы проектын әзерләү, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары редакциясенә кабул ителгән карар турында хәбәр итү министрлыкның матбугат хезмәтләре һәм җәмәгатьчелек белән элемтә бүлеге тарафыннан әлеге Кагыйдәләрдә билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда гамәлгә ашырыла.

## IV. Аккредитацияләнгән журналистларның хокуклары һәм бурычлары

4.1. Аккредитацияләнгән журналистлар түбәндәге хокукларга ия:

чарада катнашырга;

министрлык карамагындагы чара турында рәсми документларның (көн тәртибе, пресс-релизлар, мәгълүмати-белешмә, статистик, аналитик һәм башка материаллар) күчермәләрен алырга;

бастыру өчен әзерләнгән мәгълүмати-белешмә материаллар белән танышырга;

Россия Федерациясе законнарында каралган башка хокуклар.

4.2. Аккредитацияләнгән журналистлар бурычлы:

чараның регламентын үтәргә һәм массакүләм мәгълүмат чаралары өчен махсус оештырылмаган очракта, аның барышына катышмаска;

чарада катнашучылар эшчәнлегенә комачауламаска;

Министрлык тарафыннан бирелгән публикацияләрдә (эфирда) пресс-релизлардан, мәгълүмат-белешмә, статистик, аналитик һәм башка Материаллардан файдаланганда мәгълүмат чыганагына таянырга;

үз һөнәри эшчәнлеген тормышка ашырганда Министрлык эшчәнлеге турында чынбарлыкка туры килми торган мәгълүмат таратмаска.